**Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең**
**11 нче сыйныфында укучы татар балалары өчен**
**татар теленнән үткәрелә торган республика олимпиадасының**
**муниципаль этабы өчен биремнәр**
**(2014/2015 нче уку елы)**

I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез

1. Кайсы табышмакта тартыкларның кире ассимиляциясе күзәтелә? Табышмакларның җавабын да языгыз.

а) Бабай килгән сагынып,
Ак чикмәнен ябынып;(Кыш)

ә) Юк аягы, юк күзе,
Безне өйрәтә үзе; (Китап)

б) Күтәреп була, ыргытып булмый; (Мамык)

в) Күккә менә, җиргә төшми,
Җиргә төшә, күккә менми. (Төтен, яңгыр)

2. Тартык авазларны яңгырау һәм саңгырауларга бүлү кайсы сөйләм органына бәйле?

а) бронхларга;
ә) тавыш ярыларына;
б) борын куышлыгына;
в) авыз куышлыгына.

3. Җөмләдә сингармонизмның ике төренә дә буйсынган ничә сүз бар?

*Китапларның гомерләре нихәтле озын, туган еллары ничаклы борынгы булса, аларның кадерләре дә шулкадәр олы, зур*. (М.Г.)

а) 3;
ә) 4;
б) 5;
в) 6

4. *п* авазына туры килгән билгеләмәне табыгыз.

а) ирен-ирен, өрелмәле, саф, шартлаулы, саңгырау, авыз авазы;
ә) ирен-ирен, йомык, саф, шартлаулы, шаулы, саңгырау, авыз авазы;
б) ирен-теш, йомык, саф, сонор, авыз авазы;
в) ирен-ирен, йомык, саф, аффрикат, сонор, авыз авазы.

5. Бирелгән фразеологик әйтелмәләрнең русча эквивалентларын языгыз (тәрҗемәсен түгел!)

а) урманга утын төяп бару - (ехать в Тулу со своим самоваром)
ә) кызыл кар яугач - (когда рак на горе свистнет)
б) ике агач арасында адашу - (заблудиться в трех соснах)
в) балтасы суга төшкән кебек - (как в воду опущенный)

6. Сүзгә этимологик анализ ясаганда файдаланылмый торган чыганак –

а) фольклор әсәрләре;
ә) язма истәлекләр;
б) археологик табылдыклар;
в) сүзлекләр һәм матур әдәбият.

7. Хәзерге татар әдәби теле нинди үсеш этаплары үткән?

а) борынгы гомуми төрки әдәби теле → иске гомуми төрки әдәби теле → иске татар әдәби теле → хәзерге татар әдәби теле;

ә) иске гомуми төрки әдәби теле → борынгы гомуми төрки әдәби теле → иске татар язма әдәби теле → хәзерге татар әдәби теле;

б) гомуми төрки әдәби теле → иске төрки әдәби теле → иске татар әдәби теле → хәзерге татар әдәби теле;

в) иске төрки әдәби теле → гомумтөрки әдәби теле → татар милли әдәби язма теле → хәзерге татар әдәби теле.

8. Рецензия жанры кайсы стильгә карый?

а) фәнни;
ә) рәсми эш кәгазьләре;
б) публицистик;
в) матур әдәбият стиле.

9. Кайсы җөмләдә тезмә сүз бар?

а) Туфанның гомерендә яратып яшәгән урыны - бик матур түгәрәк күл буе.
ә) Ерак сәфәрләрдән соң арып килгән урыны, дачасы, бакчасы шул.
б) Тургай чәчәге белән ромашкалардан башлап, бөтен чәчәкләр дә бар анда.
в) Көз җиткәч, алардан букет ясап, Тукай һәйкәленә илтә (С.Х.).

10. Бер сүз төркеменнән икенчесенә күчү юлы белән ясалган сүзләр кайсы төркемдә?

а) очучы, үлчәү, белдерү, яттан;
ә) тимерче, кибетче, эшче, тәрбияче;
б) бәләкәй, хикәят, әмәл, әзер;
в) бүген, быел, унбиш, матурай.

11. *Килгәләгәннәр* сүзендәге икенче морфема нәрсәне белдерә?

а) эшнең тәмамланмавын;
ә) эшнең нәтиҗәле башкарылуын;
б) эшнең кабатлануын;
в) эшнең үткәндә башкарылуын.

12. -*мага*/-*мәгә* кушымчалары – ...

а) хикәя фигыльнең үткән заман күрсәткече;
ә) сыйфат фигыльнең юклык формасы;
б) фигыльнең юклык күрсәткече;
в) инфинитивның диалекталь формасы.

13. *Кояш үз юлы белән әкрен генә төшеп бара* (И.Гази) җөмләсендә *бара* сүзе:

а) мөстәкыйль фигыль;
ә) ярдәмче фигыль;
б) ярдәмче фигыль функциясендә килгән мөстәкыйль фигыль;
в) мөстәкыйль фигыль функциясендә килгән ярдәмче фигыль.

14. Тәкъдим ителгән раслауларның кайсы дөрес?

а) саннар башка сүз төркемнәреннән ясалмый;
ә) саннардан башка сүз төркемнәре ясалмый;
б) саннар җөмлә кисәге булып килми;
в) саннар башка сүз төркемнәреннән ясала.

15. Хәзерге заман сыйфат фигыльнең гади формасы ...

а) даими үтәлә торган эшне;
ә) кайвакыт эшләнә торган эшне;
б) затка бәйле эшне;
в) сөйләм вакытына туры килмәгән эшне билге итеп белдерә.

16. Кайсы җөмләдә кисәкчә юк?

*а) Әллә күпкә, әллә бик озакка,*
*Ахры, мәңге оныта алмамын...* (Һ.Такташ)
*ә) Ассалар да, киссәләр дә,*
*Үлмәдең син, калдың тере* (К. Нәҗми)
*б) Төрки телләр шактый аерылышкан...*
*Сүзләр бер үк... Мәгънә – төрлерәк...* (Р. Харис)
*в) И туган тел!*
*Югалмадың,*
*Югалтмадың безне –*
*Халык исән калган Син барга* (Рәшит Әхмәтҗанов)

17. Җөмләнең төрен билгеләгез.

*Боз катлавы эрегәч, җир өстенә*
*Умырзая чыга, карагыз* (Ә.Ф.)

а) тиңдәш иярүле, күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;
ә) бер-бер артлы иярүле, күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;
б) катнаш кушма җөмлә;
в) иярченле кушма җөмлә.

18. Ничә синоним җөмлә бар?

*1) Башымнан давыл үтсә дә, ул давылдан сынмадым. 2) Башымнан давыл үткәндә дә, ул давылдан сынмадым. 3) Башымнан давыл үтүгә карамастан, ул давылдан сынмадым. 4) Башымнан давыл үтте, тик ул давылдан сынмадым. 5) Башымнан давыл үтте, шулай да ул давылдан сынмадым. 6) Башымнан давыл үтте, шуңа карамастан ул давылдан сынмадым. 7) Башымнан давыл үтте – ул давылдан сынмадым.*

а) 3;
ә) 6;
б) 4;
в) 5.

19. Кайсы раслау дөрес?
Катнаш кушма җөмләдә кимендә ...

а) ике оештыручы үзәк;
ә) өч оештыручы үзәк;
б) дүрт оештыручы үзәк;
в) биш оештыручы үзәк булырга тиеш.

20. Тыныш билгеләре куюның дөрес вариантын билгеләгез.

*Апрель (1) безнең өчен (2) тәнендә татар йөрәге типкән адәм балалары өчен (3) аеруча якын (4) һәм үз (5) чөнки ул (6) безгә Бөек Тукайны бүләк итте* (Х. Миңнегулов)

а) 1, 2, 3, 5;
ә) 2, 3, 5, 6;
б) 2, 3, 5;
в) 2, 3, 4, 5.

II. Теоретик бирем.

Сүзләрне төркемләү принциплары. Татар телендә сүз төркемнәре системасы.

III. Гамәли бирем 11

*Без Галимҗан Ибраһимов яши яши торган Халтурин урамындагы бишенче йортка барып кергән чакта, кояш үзенең көндезге горурлыгын югалткан иде инде.* (К.Сабиров).

1. Тыныш билгеләрен куярга.
2. Җөмлә чикләрен билгеләп, бәйләүче чараларны күрсәтергә.
3. Җөмлә кисәкләренең асларына сызарга.
4. Җөмләнең схемасын сызарга, төрен билгеләргә.
5. *Көндез* сүзенә фонетик анализ ясарга.
6. *Үзенең, яши торган, бишенче* сүзләренә морфологик анализ ясарга.
7. *Урамындагы* сүзен төзелеше һәм ясалышы буенча тикшерергә.

IV. Иҗади бирем

Татар теле – минем туган телем.
Туган телгә юк үлем!
Телең белән ачыла, халкым,
Чишмәдәй саф күңелең!..

Р.Әхмәтҗанов

Әлеге шигъри юллар Сездә нинди хисләр уята? Фикерләрегезне 12-14 җөмләдән артмаган бәйләнешле текст итеп языгыз.